РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
БУИНСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ СТАРОТИНЧАЛИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ИСКЕ ТИНЧӘЛЕ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

«03» июль 2023ел № 17

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Иске Тинчәле авыл җирлеге территориясендә хайваннарны хуҗалардан башка кайтару тыела торган урыннар исемлеген һәм хайваннарны аларның хуҗаларыннан башка аларның элеккеге яшәү урыннарына кайтару турында карар кабул итүгә вәкаләтле затлар исемлеген раслау турында

"Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, "Хайваннар белән җаваплы мөгамәлә турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында" 2018 елның 27 декабрендәге 498-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясындагы 6.1 өлеше нигезендә, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Иске Тинчәле авыл җирлеге башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Хайваннарны хуҗалардан башка кайтару тыела торган урыннар исемлеген расларга (1 нче кушымта).
2. Хайваннарны аларның хуҗаларыннан башка аларның элеккеге яшәү урыннарына кайтару турында карар кабул итүгә вәкаләтле затлар исемлеген расларга ( 2 нче кушымта).
3. Әлеге карар имза салынган вакыттан үз көченә керә һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/, шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында http://buinsk.tatarstan.ru адресы буенча урнаштырылырга тиеш.
4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Татарстан Республикасы Буа
муниципаль районының Иске Тинчәле
авыл җирлеге башкарма комитеты
җитәкчесенең урынбасары И.Х. Заббарова

ТР Буа муниципаль районының Иске Тинчәле
авыл җирлеге башкарма комитетының
2023 елның 3 июлендәге 17 номерлы карарына
1 нче кушымта

Хайваннарны хуҗалардан башка кайтару тыела торган урыннар исемлеге

Башка хайваннарга яки кешегә карата мотивациясез агрессивлык күрсәтмәгән хуҗаларсыз хайваннарны хайваннар өчен приютта стерилизация, тамгалау, исәпкә алу, карантин, дәвалау, вакцинация буенча чаралар тәмамланганнан соң, мондый хайваннарны приютта тоту мөмкинлеге булмаган очракта элеккеге яшәү урыннарына (аулау урыннары) кайтару тыела, түбәндәге территорияләргә һәм территорияләрдән 500 метрдан якынрак аралыкта:

- социаль өлкә учреждениеләре,
- сәламәтлек саклау объектлары,
- мәгариф учреждениеләре (мәктәпләр, балалар бакчалары),
- балалар һәм спорт мәйданчыклары,
- иҗтимагый киңлекләр (бакчалар, парклар, скверлар);
- сәүдә объектлары.

ТР Буа муниципаль районының Иске Тинчәле
авыл җирлеге башкарма комитетының
2023 елның 3 июлендәге 17 номерлы карарына
2 нче кушымта

Хайваннарны аларның хуҗаларыннан башка аларның элеккеге яшәү урыннарына кайтару турында карар кабул итүгә вәкаләтле затлар исемлеге

1. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Иске Тинчәле авыл җирлеге башкарма комитеты секретаре.